**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЯЛАУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯЛАУР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Ялаур ав. КАРАР

«07» февраль 2024 ел № 6

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлегенең Петровский поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Ялаур авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 19 февралендә 13 сәгать 00 минутка Петровский поселогы, Лесная урамы 19нчы йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Петровский поселогы Лесная урамындагы 2-32 нче йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Ялаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, 2024 елда 5500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Петровский торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге поселок эчендәге юлларны ремонтлау (юл япмасын күтәрү, сатып алу, ташу, вак таш салу, транспорт хезмәтләре) шул исәптән поселок эчендәге юлларны сезонлы карап тоту;

роторлы чапкыч сатып алу;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлегенең Петровский торак пунктында гражданнар Җыенының 2023 елның 16 октябрендәге 6 номерлы карарының үз көчен югалтуын танырга;

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлегенең Петровский поселогы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 октябрендәге 5 номерлы карарның үз көчен югалтуын танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында

http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Петровский торак пунктының мәгълүмати стендларында, гражданнар җыены этаплары уздырылганчыга кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча. халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Ялаур авыл җирлеге башлыгы О.В.Охотникова